РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**Исполнительный комитет Уразаевского сельского поселения Азнакаевского муниципального района**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**Азнакай муниципаль районы Уразай авыл жирлеге башкарма комитеты**

ул. Энгельса д. 65, село Уразаево,
Азнакаевского муниципального района РТ, 423330
Тел. (8-885592) 43555

Энгельс урамы ,65, Уразай авылы
Азнакай муниципаль районы ТР, 423330
Тел. (8-885592) 43555

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«23» сентябрь 2019 ел №36

Референдум үткәрү инициативасы турында

12.06.2002 ел № 67-ФЗ «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 15 статьясы, 06.10.2003 ел №131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 22, 56 статьялары, 24.03.2004 ел №23-ТРЗ «Җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 17 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Уразай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә, карар чыгарам:

1. Түбәндәге сорау буенча җирле референдум үткәрү инициативасы белән чыгарга:

«Сез 2020 елда Уразай авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 2 группа инвалидлар, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләүне киметеп, аны 200 сум күләмендә билгеләп, 400 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- асфальт түшәмәле юлларның чокырларын ремонтлау Уразай авылы,Речная хэм Подгорная урамнары;
- Уразай авылында урамнарны яктырту, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, энергияне саклый торган лампаларны урнаштыру;
- Уразай авыл территориясен җыештыру, көнкүреш калдыкларын һәм чүп-чарларны җыю;
-Уразай авыл халкынын ялын оештыру, бэйрэмнэр үткәрү(Җиңү бәйрәме,Сабантуй, балаларны яклау коне,халыкара өлкәннәр көне),
- Уразай авылында янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру;
- Уразай авылында юлларны кардан чистарту;
- Уразай авылында җәй көне территорияне чабу;
-Уразай авылында һәлак булган сугышчылар һәйкәлен ремонтлау;
-Уразай авылында коры агачларны, куакларны кисү, гербицид белән тоташ химик эшкәртү уткэру.

ӘЙЕ ЮК».

2. Әлеге карар түбәндәге чаралар аша халыкка игълан ителергә тиеш:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Уразай авылы, Энгельс ур., 65 йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында;

- Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru,

- Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

Башлык: А.М.Шарифуллина